Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«13» ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 13 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Яңа Әмзә авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 221 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 146 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 146 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Яңа Әмзә авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль

районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.Ә. Насыйбуллин

Әмзә авыл җирлеге башлыгы А.Ә. Насыйбуллин